ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе**
Кама Тамагы районы,
Келәнче авылы
тел. 8-(84377)- 33-4-31

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Руководитель Исполнительного комитета Клянчеевского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Клянчеево
тел. 8-(84377)- 33-4-31

---

**КАРАР**

**14.03.2019 г.** **№ 9**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законы, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 24 гыйнварындагы № 32» 2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында " карарларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегендә 2019 елның 1 февраленнән башлап җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен бирә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам

Җитәкче Д.А.Кадыров

1 кушымта

Кама Тамагы муниципаль районы

Келәнче авыл җирлеге

Башкарма комитеты карарына

14.03. 2019  № 9

2019 елның 1 февраленнән башлап Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенэ бэялэр

| **Хезмэт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бэясе** |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.  Җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3563,28 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 507,06 |
| Җирләү (кабер казу һәм күмүгә) | 1876,13 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

2 кушымта

Кама Тамагы муниципаль районы

Келәнче авыл җирлеге

Башкарма комитеты карарына

14.03 2019 № 9

2019 елның 1 февраленнән башлап Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә бәяләр

| **Хезмэт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
| --- | --- |
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 182,86 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3380,42 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) ташу | 507,06 |
| 4.Җирләү (кабер казу һәм күмүгә) | 1876,13 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |